# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында”
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 мартында
кабул ителде

**1 статья**

“Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында” 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 26 маендагы 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 11; 2005, № 5; 2009, № 6; 2012, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:
а) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“яшь гражданнар (яшьләр) – 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге затлар;”;
б) бишенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 10 статьяда:
а) исемендә “һәм яшьләр” сүзләрен “, яшьләр һәм балалар” сүзләренә алмаштырырга;
б) беренче һәм икенче абзацларда “һәм яшьләр” сүзләрен “, яшьләр һәм балалар” сүзләренә алмаштырырга;
в) өченче һәм бишенче абзацларда “яшьләр” сүзеннән соң “һәм балалар” сүзләрен өстәргә;

3) 11 статьяда:
а) исемендә “яшьләр” сүзеннән соң “һәм балалар” сүзләрен өстәргә;
б) текстта “яшьләр” сүзеннән соң “һәм балалар” сүзләрен өстәргә;

4) 14 статьяның икенче абзацында “һәм яшьләр” сүзләрен “, яшьләр һәм балалар” сүзләренә алмаштырырга;

5) 15 статьяның беренче абзацында “яшьләр” сүзеннән соң “һәм балалар” сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2013 елның 11 апреле
№ 26-ТРЗ